ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 426 от «12» 12 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"06.10.2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктын һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында гы 1өлешенең 1 пунктын гамәлгә ашыру максатларында, 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге «Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми,урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 44 номерлы карарына (алаг таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Карарның 1 нче Кушымтасының 4.7. пунктындагы "мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле якынча белем бирү программаларын исәпкә алып" сүзләрен “мәктәпкәчә белем .бирүнең тиешле федераль программасы белән” сүзләренә алыштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Белем бирү оешмалары тарафыннан эшләнгән белем бирү программаларының эчтәлеге һәм планлаштырылган нәтиҗәләре федераль мәктәпкәчә белем бирү программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбән булмаска тиеш.”

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карары 2023 елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

0000011508

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов